ГОСУДАРСТВЕННЫЙ
КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
ТАРИФЛАР БУЕНЧА
ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

---

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

**от 04.12.2014** г. Казань **№ 387**

**Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитетының норматив булмаган характердагы хокукый актларын бастыру һәм гамәлгә кертү тәртибе турында**

“Татарстан Республикасы норматив хокукый актларының бердәм банкы турында” Татарстан Республикасы Президентының 2002 елның 8 май № УП-352 Указы, “Башкарма хакимиятнең республика органнарының норматив хокукый актларын әзерләү, аларны дәүләт теркәве һәм бастыру Кагыйдәләре турында” Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 18.07.2002 № 426 карары нигезендә,

боерам:

1. Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитетының дәүләт Татарстан Республикасы юстиция Министрлыгы таныган, дәүләт теркәвенә мохтаҗ булмаган хокукый актлары “Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм күрсәтмәләре һәм башкарма хакимиятнең республика органнары норматив актлары җыентыгы” журналында басылырга тиеш.

2. Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитетының закон таләпләре нигезендә рәсми басылырга тиешле башка хокукый актлары, дәүләт серен билгеләүче яки яшерен характердагы белешмәләрдән торган актлар яки аларның аерым нигезләмәләреннән тыш, “Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм күрсәтмәләре һәм башкарма хакимиятнең республика органнары норматив актлары җыентыгы” журналында басылырга тиеш.

3. Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитетының, шушы боерыкның 1 һәм 2 пунктларында күрсәтелгән хокукый актлары, аларның

гамәлгә керү вакыты башкача күздә тотылмаса, рәсми басылган датадан башлап, гамәлгә керә.

4. Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитетының тариф карарларын кабул итүне оештыру, контроль һәм җиткерү бүлегенә, шушы боерыкның 1 һәм 2 пунктларында күрсәтелгән хокукый актларны, юридик бүлек белән килештереп, "Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм күрсәтмәләре һәм башкарма хакимиятнең республика органнары норматив актлары җыентыгы" журналында бастыруга җибәрүне тәэмин итәргә.

5.Шушы боерык, рәсми басылгач ун көннән соң, үз көченә керә.

6. Шушы боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Рәис М.Р. Зарипов